**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Березка, ул. Новостройка,15А

422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы., Новостройка ур., 15А

Тел./факс 8(84365) 79-2-08, e-mail:Berez.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 июль, 2022 ел** **№ 54**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 34 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 07.08.2020 № 50, 15.01.2021№ 17 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Каенлык авыл җирлеге Советының 2021 елның 4 октябрендагы 35 нче номерлы « «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Каенлык авыл җирлеге Советының 2021 елның 4 октябрендагы 35 нче номерлы « «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 25 октябренда 17.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Биектау районы, Каенлык авылы, Үзәк урамы, 12 нче йорт, үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл

җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 34 номерлы карары белән кабул ителгән ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 07.08.2020 № 50, 15.01.2021№ 17 карарлары редакциясендә) проектын, федеральһәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы
урынбасары В.В.Виноградов